ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАТАР
ЧаАЛМАНАРАТ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423752, Чалманарат авылы,
Узэк ур.,2 нче йорт.
Тел/факс 3-44-64

СОВЕТ ЧАЛМАНАРАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423752, село Чалманарат,
ул.Центральная,дом 2.
Тел/факс 3-44-64

**РЕШЕНИЕ**
**«29» ноябрь 2019 ел**

**КАРАР**
**№ 27**

**Чалманарат авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 29.11.2019 елгы гражданнар җыены беркетмәләре нигезендә Чалманарат авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Чалманарат авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 1 төркем инвалидлардан кала, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан кала, 2020 елда үзара салымның бер тапкыр 500(Биш йөз) сум түләвен кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

* Күмү урыннарын карап тоту:
-ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;
- Күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
*җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру

- җирлек торак пунктларында хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм киртәләү.;
- торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;
- җирлек торак пунктында Игъланнар тактасы ясау һәм аларны урнаштыру;;
- җирлек территориясендә хуҗасыз объектларны сүтү;
* автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдлау, кардан чистарту)
* җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру
-торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;;
* урам утларын реконструкцияләү.
-урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту

2. Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Чалманарат авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы К.С.Ахметов